# С Ы Й Ф А Т

Предметның билгесен белдереп,нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына җавап бирүче мөстәкыйль сүз төркеме

**Тышта ак кар ява**

**Бу җөмләдә карның ак төстә булуы әйтелә. Бу җөмләдә без карның тик ак икәнен генә беләбез. Һәм бу сыйфатның гади дәрәҗәсе була**

**Ак, зәңгәр, матур, яшел, сары, чибәр, зур, кечкенә**

**Беренче шар икенчесеннән кызылрак**

Бу җөмләдә сыйфат шарның кызылрак икәнен хәбәр итә, ягъни аны икенче шар белән чагыштыра.

**Гади дәрәҗә+ рак, - рәк кушымчасы= чагыштыру дәрәҗәсе**

**Кызылрак, зәңгәррәк, олырак, кечкенәрәк, матуррак, озынрак**

Бу алма кып – кызыл
булып пешкән

**Бу җөмләдә сыйфат алманың нык кызыл булуын, артыгыннан бигрәк кызаруын күрсәтә.**

1. **Көчәйткеч кисәкчә(кып-,кап-зәп-, сап-,ямь-)+ гади дәрәҗә= артыклык дәрәҗәсе**

2. **Иң, үтә,дөм, җете кисәкчәләре + гади дәрәҗә = артыклык дәрәҗәсе**

3. **Сыйфатларның кабатлануы = артыклык дәрәҗәсе**

Сап-сары,кап-кара, зәп-зәңгәр, ямь-яшел.
Иң матур, үтә чибәр, җете кызыл, дөм сукыр.
Кызылның кызылы, матурның матуры, сарының сарысы.

# Күлнең суы зәңгәрсу төстә иде

**Бу җөмләдә сыйфат күлнең зәңгәрдән ачыграк булуын күрсәтә, кимлек билгесен өсти.**

Гади дәрәҗә+ -су, -гылт,

-кылт, -келт,

-кылтым, - келтем, -елҗем, -

сыл кушымчалары =

кимлек дәрәҗәсе

Зәңгәрсу, кызгылт, ачкылт, яшькелт, ачкылтым, төчкелтем, күгелҗем, аксыл

**ТӘМАМ!**

**Игътибарыгыз өчен**

**ЗУР РӘХМӘТ!!!**